ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 128-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары А.Р. Габделҗанов, М.Һ. Галиев, Р.Г. Хөсәенов тарафыннан кертелгән «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 128-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре
2025 елның 24 декабре
№ 499-VII ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
А.Р. Габделҗанов,
М.Һ. Галиев,
Р.Г. Хөсәенов
тарафыннан кертелә

**Административ хокук бозулар турында**
**Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**1 статья**

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 9 – 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 3, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 10 (II өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2012, № 1, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 1, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 7, № 10; 2014, № 1 – 2, № 5, № 6 (I өлеш), № 7; 2015, № 3, № 4, № 12 (I өлеш); 2016, № 5, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 85 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2020, № 37 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш); 2022, № 49 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 56 (I өлеш); 2024, № 56 (I өлеш), № 81 (I өлеш); 2025, № 1 (I өлеш), № 18 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 56 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 2.23 статья өстәргә:

«2.23 статья. **Тонусны күтәрә торган алкогольсез (шул исәптән энергетик) эчемлекләр сатуга тыюларны һәм чикләүләрне үтәмәү**

Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тонусны күтәрә торган алкогольсез (шул исәптән энергетик) эчемлекләр сатуга тыюларны һәм чикләүләрне үтәмәгән өчен –

гражданнарга – өч меңнән алып биш мең сумга кадәр; вазыйфаи затларга – утыз меңнән алып илле мең сумга кадәр; юридик затларга йөз меңнән алып йөз илле мең сумга кадәр административ штраф салына.»;

2) 7 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 7.11 статья өстәргә:

«7.11 статья. **Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең тонусны күтәрә торган алкогольсез (шул исәптән энергетик) эчемлекләр сату өлкәсендә региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы органы**

1. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең тонусны күтәрә торган алкогольсез (шул исәптән энергетик) эчемлекләр сату өлкәсендә региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы органы әлеге Кодексның 2.23 статьясында каралган административ хокук бозулар турындагы эшләрне карый.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән орган исеменнән административ хокук бозулар турындагы эшләрне Татарстан Республикасы Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүгә, аларның әйләнешенә һәм сыйфатына дәүләт контролен тәэмин итү һәм кулланучыларның хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе җитәкчесе, аның урынбасарлары, Татарстан Республикасы Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүгә, аларның әйләнешенә һәм сыйфатына дәүләт контролен тәэмин итү һәм кулланучыларның хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясенең территориаль органнары башлыклары карый.»;

3) 8.1 статьяда:

а) «7.10» саннарыннан соң «, 7.11» саннарын өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле $10^1$ өлеш өстәргә:

«$10^1$. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән очраклардан тыш, әлеге Кодексның 2.23 статьясында каралган административ хокук бозулар турындагы беркетмәләрне Татарстан Республикасы Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүгә, аларның әйләнешенә һәм сыйфатына дәүләт контролен тәэмин итү һәм кулланучыларның хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе һәм аның территориаль органнары структур бүлекчәләренең вазыйфаи затлары төзи.».

**2 статья**

Әлеге Закон 2026 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**
**АҢЛАТМА**

«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты «Татарстан Республикасы территориясендә тонусны күтәрә торган алкогольсез (шул исәптән энергетик) эчемлекләр сатуга тыюлар һәм чикләүләр турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүгә бәйле эшләнде, анда Россия Федерациясе субъектына «Балигъ булмаганнарга тонусны күтәрә торган алкогольсез (шул исәптән энергетик) эчемлекләр сатуны тыю турында һәм «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның төп принциплары турында» Федераль законның 44 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2024 елның 8 августындагы 304-ФЗ номерлы Федераль закон белән бирелгән хокукны гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы территориясендә тонусны күтәрә торган алкогольсез (шул исәптән энергетик) эчемлекләр сатуга тыюлар һәм чикләүләр билгеләү тәкъдим ителә.

Закон проектында Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына югарыда күрсәтелгән тыюларны һәм чикләүләрне үтәмәгән өчен гражданнарга өч меңнән алып биш мең сумга кадәр; вазыйфаи затларга утыз меңнән алып илле мең сумга кадәр; юридик затларга йөз меңнән алып йөз илле мең сумга кадәр штрафлар рәвешендә җаваплылык билгели торган 2.23 статья өстәү тәкъдим ителә. Административ хокук бозулар турындагы эшләрне ачу компетенциясен Татарстан Республикасы Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүгә, аларның әйләнешенә һәм сыйфатына дәүләт контролен тәэмин итү һәм кулланучыларның хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе һәм аның территориаль органнары вазыйфаи затларына, ә күрсәтелгән эшләрне карау компетенциясен Татарстан Республикасы Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүгә, аларның әйләнешенә һәм сыйфатына дәүләт контролен тәэмин итү һәм кулланучыларның хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе җитәкчесенә, аның урынбасарларына, территориаль органнары башлыкларына беркетү тәкъдим ителә.

Әлеге законның үз көченә керү датасы итеп 2026 елның 1 сентябрен билгеләү тәкъдим ителә.

**«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында»Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

**«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән каплана торган өстәмә чыгымнар таләп итми.